| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
|---|---|
| СОВЕТ БОЛЬШЕШИНАРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ ШЫҢАР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
| 422054, Республика Татарстан, Сабинский район,<br>с.Большой Шинар, ул. Кооперативная, 36<br>тел. (84362) 41-2-11 | 422054, Татарстан Республикасы, Саба районы,<br>Олы Шыңар авылы, Кооператив урамы, 36 йорт<br>тел. (84362) 41-2-11 |

e-mail: bshin.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ — КАРАР

09.02.2018 — №3

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Олы Шыңар авыл җирлеге Советының
"Олы Шыңар авыл җирлегендә халык алдында
тыңлаулар турында нигезләмәне раслау турында"
29.11.2006 ел 30а номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

ТР Саба районы прокуратурасының 31.01.2018 ел №02-08-02-5-2018 ризасызлыгы нигезендә Олы Шыңар авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. Олы Шыңар авыл җирлеге Советының 29.11.2006 ел 30а номерлы карары белән расланган "Халык алдында тыңлаулар турында нигезләмәнең 3.1 пунктын түбәндәгечә бәян итәргә:

   "Халык алдында тыңлауларга түбәндәгеләр чыгарыла:
   - муниципаль берәмлек уставына РФ Конституциясе нигезләмәләрен, федераль законнарны, РФ субъектлары законнары яки конституциясен (уставын)төгәл күрсәтү формасында үзгәрешләр кертү очрагыннан башка, муниципаль берәмлек уставының проекты, шулай ук әлеге уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль норматив-хокукый акт проекты, бирелгән уставны әлеге норматив-хокукый актларга туры китерү максатында;
   - җирле бюджетһәм аның үтәлеше турында хисап проекты;
   - муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый үсеш проекты;
   - гамәлдәге законнар нигезендә муниципаль берәмлекне үзгәртеп кору өчен муниципаль берәмлектә яшәүче халыкның рөхсәтен тавыш бирү юлы белән яисә халык җыенында алу таләп ителгән очраклардан тыш, муниципаль берәмлекне үзгәртеп кору турында сораулар;
   - генераль план проектлары буенча, җирдән файдалану һәм төзү кагыйдәләре проекты, биләмәне планлаштыру проектлары, биләмәне төзекләндерү кагыйдәләре проектлары; күрсәтелгән, расланган документларга үзгәрешләр кертүне күздә тоткан проектлар; шартлы рәвештә рөхсәт ителгән җир кишәрлеге яки капиталь төзелеш объектын куллануга рөхсәт бирү турында карарлар проекты; рөхсәт ителгән төзелеш параметрлары чигеннән читкә чыгу рөхсәтен бирү, капиталь төзелеш объектларын яңадан үзгәртеп төзү карарлары проекты; җирдән файдалану һәм төзү кагыйдәләре булмаган очракта җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектларын бер рөхсәт ителгән файдалану төреннән

икенчесенә күчерү мәсәләсе буенча халык алдында тыңлаулар үткәрелә; оештыру һәм үткәрү тәртибе шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закончалыкның нигезләмәләрен һәм җирлекнең аерым муниципаль норматив-хокукый актларын исәпкә алып билгеләнә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырырга.
3. Карар рәсми бастырып чыгарган көннән үз көченә керә.
4. Карарның үтәлешен тикшерүне үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы А.Г.Гарипов